| СОВЕТ НОВОКИРЕМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КАРМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.04.2026ел с.Новая Киреметь №22

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советы 27.11.2018 ел, №73 «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 26 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 171 статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 26 февралендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәтавыл җирлеге Советы КАРАРЫ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында» 27.11.2018 ел, № 73 карары белән расланды) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 19.1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.»;

2) 19.2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон) мондый белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм формада каралган чыгымнар турында белешмәләр тапшырырга тиеш.»;

3) 19.3 өлештә «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 19.4 өлештә «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 19.5 өлештә «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр,» сүзләренә алмаштырырга;

6) 19.6 өлештә «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр,» сүзләренә алмаштырырга;

7) 19.7 өлештә «үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законда каралган чыгымнар хакында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

8) 19.8 өлештә «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр,» сүзләренә алмаштырырга;

9) 19.10 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыра, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башлыгына (Рәис) тапшыра.»;

10) 19.11 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

11) 19.12 өлештә «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр,» сүзләренә алмаштырырга;

12) 19.13 өлештә «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 20.3 өлешнең 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;».

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы сайтында интернет челтәрендә http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Карар басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Аксубай муниципаль районы
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы: И.Р.Шакиров